СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 12-42

от «11» апреля 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 декабрендәге 1721 номерлы карары, Министрның беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д. Фәйзрахмановның 2024 елның 8 февралендәге № 08-14/475 номерлы хаты нигезендә , Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.2025 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы финанс-бюджет палатасының бюджет бүлегеннән баш белгеч муниципаль хезмәт вазыйфасын чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасының штат расписаниесенә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгы В.И.Никитин

000032